| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 528-106/тэ-2020

«ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә тарифлар билгеләү һәм Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының аерым карарларын гамәлдән чыккан дип тану турында

Татарстан Республикасы Югары судының 15.05.2020 № 3а-234/2020 карарын һәм Гомуми юрисдикциядәге дүртенче апелляция судының 30.09.2020 №66-1643/2020 карарын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелүче җылылык энергиясе тапшыру хезмәтләренә, шушы карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карар 2019 елның 26 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә була, дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип танырга:

«ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте күрсәтә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтләренә тарифлар билгеләү хакында» 26.04.2019 № 5-1/тэ;

«Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган җылылык энергиясен тапшыру хезмәтенә тарифлар билгеләү турында» 26.04.2019 № 5-1/тэ карары кушымтасына үзгәреш кертү турында» 30.09.2019 № 5-6/тэ.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 528-106/тэ-2020
карарына кушымта

«ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан җылылык энергиясен тапшыру хезмәте күрсәтүгә тарифлар

<table>
<tr><th rowspan="2">т/с</th><th rowspan="2">Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы</th><th rowspan="2">Тариф төре</th><th rowspan="2">Ел</th><th colspan="2">Җылылык энергиясен тапшыру матдәсенең төре</th></tr>
<tr><th>су</th><th>пар</th></tr>
<tr><td></td><td colspan="5">Зеленодольск муниципаль районы, Осиново авыл җирлеге</td></tr>
<tr><td rowspan="3">1</td><td rowspan="3">«ПЭСТ» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте</td><td colspan="4">Тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта, – кулланучылар өчен</td></tr>
<tr><td rowspan="2">бер ставкалы, сум/Гкал</td><td>26.04.2019 башлап 30.06.2019 кадәр</td><td>315,43</td><td>-</td></tr>
<tr><td>01.07.2019 башлап 31.12.2019 кадәр</td><td>319,83</td><td>-</td></tr>
</table>

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге